КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 июль г.Казань № 678

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 16 август, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 16 август, 732 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2021 ел, 16 декабрь, 1240 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «уздыруга» сүзеннән соң «, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта татар текстында «уздыруга» сүзеннән соң «, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә татар текстында «уздыруга» сүзеннән соң «, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга» сүзләрен өстәргә;

1 пунктның беренче абзацында татар текстында «уздыруга» сүзеннән соң «, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның өченче абзацында «проектларны» сүзе алдына «мәдәният өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү срокларын, заявкалар бирелә башлау яки кабул итү тәмамлану датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау.»;

19 пунктта:

тугызынчы абзацта татар текстында «очракта –» сүзеннән соң «субсидия алучы тарафыннан» сүзләрен өстәргә, «нәтиҗәләренә ирешү» сүзләрен «нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта татар текстында «очракта –» сүзеннән соң «субсидия алучы тарафыннан» сүзләрен өстәргә, «нәтиҗәләренә ирешү» сүзләрен «нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта, субсидия алучының, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә

карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] и 269[2] статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы.»;

ундүртенче абзацта «, максатларын» сүзен төшереп калдырырга;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта, субсидия алучы Министрлыкка квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 5еннән дә соңга калмыйча, килешүнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формасына теркәлә торган формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирә.

Чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта, субсидия алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 5 еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгенгән килешүнең бертип формасына теркәлгән формалар буенча Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирә.

Кирәк булганда Министрлык килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгели.»;

28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

29 пунктның икенче абзацында «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтаның башисемендә татар текстында «уздыруга» сүзеннән соң «, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга» сүзләрен өстәргә;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 16 август, 732 нче карары белән расланган Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте,

халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 9 пунктындагы өченче абзацының, 10 пунктындагы җиденче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы егерме бишенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин